**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 20 июнендәге 1855 номерлы карары**

## 2025 елда «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) чыгым нормативларын раслау турында

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль бирем формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында»гы, 2025 елның 14 мартындагы 700 номерлы «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә 2025 елның 1 гыйнварыннан «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенең эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) чыгым нормативларын расларга һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) чыгым нормативлары муниципаль бирем буенча тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру өчен кулланыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 20 июнендәге
1855 номерлы карарына
кушымта

**«Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенең 2025 елга эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) чыгым нормативлары**

| № т/б | Күрсәтелә торган хезмәтнең (эшнең) атамасы | Хезмәтнең (эшнең) эчтәлеге | | Чыгымнарның норматив күләме (елына сумнарда) |
|---|---|---|---|---|
| | | күрсәткечнең атамасы | күрсәткечнең зурлыгы | |
| 1 | Муниципаль милектәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү), 2025 елның 1 гыйнварына торышы | Эшнең асылы | Җиһазларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү | 256 188 000 |
| 2 | Мәгълүмат ресурсларын һәм белешмәләр базасын алып бару | - | - | 29 338 579 |
| 3 | Программа белән тәэмин итү, инженерлык, исәпләү һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасы белән тәэмин итү, шул исәптән болыт технологияләре нигезендә дә | Телекоммуникация җиһазларының төре | Эшче станцияләр составыннан тыш кулланыла торган периферия һәм махсуслаштырылган җиһазлар | 32 598 421 |